**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Каргопольское сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Карга авыл жирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адрес: 422875, РТ, с. Каргополь, ул. Центральная, 30
тел: : 8 (84346) 77-8-80

Адресы: 422875, РТ, Карга авылы, Узэк ур.,30
факс: 8 (84346) 77-8-80

**Постановление Каргополь Карар**
**№ 2** **от 25 января 2022**

## Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Карга авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы "Җирләү һәм җирләү эше турында" 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы "Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында "Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында" 196 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районыныңКарга авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Әлки муниципаль район Карга авыл җирлегендә 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен кушымта нигезендә 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Карга авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 20 мартындагы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районыныңКарга авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 5 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru.порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлки муниципаль районы
Карга авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: Р.В Мингазов

Карга авыл җирлеге башкарма комитетының 2022елның 25 гыйнварындагы № 2 карарына 1 нче кушымта

Карга авыл җирлегендә 2022 елның 1 февраленнән күрсәтелә торган җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә тарифлар

| т/б № | Хезмәтләр, кирәк-яраклар исемлеге | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|---|
| 1. | 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 4011,67 |
| 3. | Мәрхүмнең мәетен (калдыгын) зиратка китерү | 1448,65 |
| 4. | Җирләү (каберне казу һәм күмү) | 1504,36 |
| | Барлыгы: | 6964,68 |

Карга авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022елның 25 гыйнварындагы №2 карарына нче кушымта

Карга авыл җирлегендә 2022 елның 1 февраленнән күрсәтелә торган җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә тарифлар

| т/б № | Хезмәтләр, кирәк-яраклар исемлеге | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|---|
| 1. | 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. | Кәфенләү | 1337,91 |
| 3. | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 2668,19 |
| 4. | Мәрхүмнең мәетен (калдыгын) зиратка китерү | 1448,65 |
| 5. | Җирләү (каберне казу һәм күмү) | 1509,93 |
| | Барлыгы: | 6964,68 |